**(Слайд 1)**

Хәерле көн хөрмәтле Нәҗип Нәкыйпович, президиум, депутатлар.

2020 ел әһәмиятле даталарга һәм иҗтимагый-сәяси вакыйгаларга бай булды: Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгы; ТАССР төзелүнең 100 еллыгы; Россия Федерациясе Конституциясенә үзгәрешләр кертүгә бәйле үткәрелгән тавыш бирү; 13 сентябрьдә булып узган Бердәм тавыш бирү көне һәм башкалар.

Төп тезисларга басым ясап, безнең эшчәнлеккә бәйле берничә цифрга тукталып узасым килә.

**(Слайд 2)** 2020 елда Республика халкы тарафыннан безнең адреска 5 859 мөрәҗәгать керде. (в 2019 году – 4 713 раз). Теләче муниципаль районы Советына һәм Теләче башкарма комитетына кергән мөрәҗәгатьләр саны 342не тәшкил итә, шулар арасыннан 134 мөрәҗәгать белән килгән кеше, Теләче муниципаль район башлыгы тарафыннан шәхси кабул ителә.

Гомумән алганда, халыкның мөрәҗәгате иҗтимагый-икътисади проблемаларны үз эченә ала, төп өлешен: торак шартларын яхшырту, иҗтимагый сораулар, юл төзелеше, торак-коммуналь хуҗалыкка карата булган сораулар тәшкил итә.

**(Слайд 3)** Шулай ук, халык белән эшләүнең үтемле формасы булып, авылларда, учреждения-предприятияләрдә уздырылучы Халык җыеннары тора. Биредә, халыкны борчыган мәсьәләләрне төрле тармак җитәкчеләре, депутатлар турыдан-туры ишетеп, күмәк рәвештә хәл итү юлларын эзли. Узган ел да, халыкны борчыган белем бирү, сәламәтлекне саклау, мәдәният, торак һәм юл төзелеше, газлаштыру, иҗтимагый яклау мәсьәләләре каралып тиешле чаралар кабул ителде.

**(Слайд 4)** Количество уведомлений ГИС РТ «Народный контроль» составило в 2020 году 76 455 заявок.

78 % из них – 59 382 уведомления – уже решены.

По Тюлячинскому муниципальному району через данный канал поступило 21 уведомление, 19 из них были решены положительно, 2 заявкам присвоен статус «запланировано» (1. Ключ авылына юл. 2. Әбде авылында мәдәният йорты булып мәктәп спортзалы тора, шуның тәрәзәләрен алыштыру).

За период 2020 года электронно (интернет приемная, электронная почта) поступило 213 обращение. “Обратная связь” обеспечивает возможность местным органам власти судить о настроениях общества и дать возможность гражданам высказывать свое мнение о социально-значимых процессах и событиях.

С 25 июня по 1 июля 2020 года в период Общероссийского голосования по вопросу одобрения изменений в Конституцию Российской Федерации и с 10 по 13 сентября 2020 года в преддверии и в Единый день голосования общественными помощниками Уполномоченного были проверены обеспечение и реализация избирательных прав граждан: посещены избирательные участки и в обязательном порядке проверялось соблюдение мер, направленных на обеспечение санитарно-эпидимиологической безопасности.

**(Слайд 5)** В 2020 году в рамках празднования Международного дня прав человека (10 декабря) и Дня Конституции Российской Федерации (12 декабря) в декабре 2020 года в

общеобразовательных организациях Республики Татарстан общественные помощники и учителя истории провели Единый урок по правам человека, все школы нашего района хорошо организовали и достойно провели все эти уроки.

**(Слайд 6, 7)** Ел дәвамында халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә озак вакыт эш эзләп исәптә торучы эшсез гражданнарга, пандемия чорында һөнәри яки өстәмә һөнәри белем алуга юлламалар бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрелде. Бу очракта безнең тәкъдимнәр кабул ителеп уңай карар кабул ителуен билгеләп үтәргә кирәк.

**(Слайды 8)** Нәтиҗәле иҗтимагый сәясәтне, бөтен төр гражданнарга да тигез шартлар тудырылуыннан башка күзалдына китереп булмый. Биредә сүз бара физик мөмкинлекләре чикле булган гражданнарның иҗтимагый хокукларын тормышка ашыру турында. Инвалидларны иҗтимагый яклау буенча законнар эшләнелешен тикшерү белән бер рәттән, узган ел бу өлкәдә безнең тарафтан аналитик тикшерү эшләре уздырылды. **(Слайд 9)**Биредә инвалидларны сәламәтләндерү, физик культура аша реабилитация һәм абилитация чаралары, спорт белән шөгелләнү өчен тудырылган мөмкинлекләр тикшерелде. **(Слайд 10)** Шунсы игътибарга лаек, Экспертлар советы тарафыннан уздырылган республика күләм «түгәрәк өстәл» киңәшмәсендә безнең Теләче районы югары бәяләнеп, мактап телгә алынды. Форсаттан файдаланып, эзлекле эш алып барганыгыз өчен, сезгә Нәҗип Нәкыйпович, һәм әлеге эшләрне башкаруда катнашкан барлык кешеләргә рәхмәтемне белдерәм.

**(Слайд 11)**Узган ел сәламәтлекне саклау системасы гадәти булмаган каршылык белән очрашты, бу исә көндәлек тормышка үзгәрешләр кертте. КОВИД-19 таралуга каршы республикада зур эшләр башкарылды. Кызганыч, әлеге изоляция чорында вакытлыча планлы медицина тикшеренүеләре туктатылып торылды. **(Слайд 12)**Әлеге эш яңартылгач, безнең тарафтан һәр кергән мөрәҗәгать исәпкә алынып, нәтиҗәләре Татарстан Республикасының Сәламәтлекне саклау министрлыгына тапшырылды. **(Слайд 13)** Сораштырулар күрсәткәнчә, безнең районда медицина ярдәменең сыйфатыннан канагать булучылар 93,5% тәшкил итеп, гомум республика күрсәткеченнән югары дәрәҗәгә ирешә алды. Әлбәттә, әлеге эш бу елны да дәвам ителә.

Шулай ук, форсаттан файдаланып районыбызның баш табибы Галиуллин Ирек Илгиз улына һәм ул җитәкләгән коллективка рәхмәтемне җиткерәм.

**(Слайд 14)** 2020 елда, коронавирус инфекциясе (Covid-19) таралуга комачаулаучы чикләү чаралары гамәлдә булуга карамастан, хокукый белем бирү эше мәгълүмати технологияләр ярдәмендә алып барылды.

Республика буенча чүп контейнерларын урнаштыру буенча 84, чүпне вакытында урнаштыру буенча 66 хәбәр керде. Әлеге исемлектә безнең район юк.

Хөрмәтле депутатлар һәм киңәшмәдә катнашучылар! Әлеге докладны әзерләгәндә безнең хезмәтебезнең көндәлек эшчәнлеген чагылдыру максат итеп куелмады. Докладта әйтеп узган тәгълимат һәм нәтиҗәләр кулланма рәвештә исәпкә алынып, районыбыз халкының көнкүреш шартларын яхшыртыр дип ышанып калам.

**(Слайд 15)** Игътибарыгыз өчен рәхмәт! Спасибо за внимание!